**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 18 «12» декабрь 2025 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогының муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы 30.12.2022 № 61 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында 28.03.2018 № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.11.2025 № 994 карары нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогының муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы 30.12.2022 № 61 карары белән расланган (30.05.2024 № 25, 21.10.2024 № 38, 28.04.2025 № 15 карарлар редакциясендә) Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлекнең 1.5 нче пунктта «15 389,00» саннарын «16 928,00» саннары белән алыштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатлар, Җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнвардан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына кушымта
«12» декабрь 2025 ел № 18

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы муниципаль хезмәткәрләренең, жирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә карата

## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләмнәре, сумнар |
|---|---|
| | Шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә оешкан авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | Унынчы төркем |
| Башлык | 27 601 |